**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 август № 573

г. Казань

2016 елда «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыятенә Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елда «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыятенә Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгын 2016 елда «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыятенә Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 август, 573 нче карары белән расланды

**2016 елда «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыятенә Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте (алга таба – «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте) арасындагы 2014 – 2016 елларга тимер юл транспорты өлкәсендә үзара ярдәм һәм хезмәттәшлек итү турында 2014 елның 29 гыйнварындагы 573 нче һәм Горький тимер юлының Свияжск станциясендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын төзекләндерү һәм капиталь ремонтлау өлкәсендә хезмәттәшлек турында 2016 елның 9 июнендәге с-746 нчы килешүләр нигезендә 2016 елда «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыятенә Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субсидия «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыятенә Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында бирелә.

3. Субсидия бирү әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында каралган максатларга Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия алу өчен «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте Министрлыкка субсидия бирү турында гариза кертә.

Субсидия бирү турындагы гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләре исемлеген үз эченә алган Пассажирларны уңайлаштыру буенча үзәк дирекция – «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте филиалының 2016 елга төп чараларын капиталь ремонтлау буенча титул исемлеге күчермәсе;

Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга шартнамә күчермәсе;

КС-2 һәм КС-3 формалары буенча Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен

капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләр акты күчермәсе.

Документларның күчермәләре «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле заты имзасы һәм мөһере белән таныклана.

5. Министрлык теркәлгән документлар белән субсидия бирү турындагы гаризаны алар кертелгән көнне кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыра.

6. Министрлык субсидия бирү турындагы гаризаны кабул иткән һәм теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия бирү хакында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 4 нче пункты таләпләренә туры килмәве Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамә тиешле карарны кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Министрлык тарафыннан «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыятенә язма рәвештә җибәрелә.

7. Субсидия чыгымнар суммасыннан 50 процент күләмендә бирелә, әмма Свияжск станциясенең түбән утрау һәм түбән яр буе платформаларын, тимер юл вокзалын һәм вокзал яны территориясен капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга шартнамә суммасыннан иң күбе 50 процент.

8. Субсидия Министрлык тарафыннан субсидия бирү хакында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте белән төзелә торган субсидия бирү турындагы шартнамә (алга таба – шартнамә) нигезендә бирелә. Шартнамә формасы Министрлык боерыгы белән раслана.

Шартнамәдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары карала.

9. Субсидия шартнамә төзегән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыятенең Россия кредит оешмасында ачылган хисап счетына күчерелә.

10. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру;

субсидия бирү шартларын үтәмәү;

субсидиядән максатка ярашсыз файдалану.

11. Шартнамәдә күздә тотылган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

12. «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыяте әлеге Тәртипнең 10 нчы һәм 11 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кайтару вакытларын бозган очракта, Министрлык субсидияне кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны мәҗбүри рәвештә кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

13. Законнар нигезендә Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы «РТЮ» ачык акционерлык җәмгыятенең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерү үткәрәләр.

14. Субсидиядән максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык гамәлгә ашыра.